СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**КАРАРЫ**

**« 14 » сентябрь 2021 ел** **№ 79**

**Арча муниципаль районы Советының 2014 елның 17 октябрендәге 295 номерлы карары белән расланган Арча муниципаль районының контроль-хисап палатасы турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (2019 елның 19 июнендәге 254 номерлы үзгәрешләр белән)**

«Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында»гы Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2001 елның 01 июлендәге, 255-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә, «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары эшчәнлеген оештыруның гомуми принциплары турында» 2011 елның 07 февралендәге 6-ФЗ номерлы Федераль законга яраклаштыру максатыннан Арча район Советы карар бирде:

1. Арча муниципаль районы Советының 2014 елның 17 октябрендәге 295 номерлы карары (2019 елның 19 июнендәге 254 номерлы үзгәрешләр белән) белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының контроль-хисап палатасы турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

**1) 3 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

**«3 статья. контроль-хисап палатасының эшчәнлек принциплары**

Контроль-хисап палатасы эшчәнлеге законлылык, гаделлек, нәтиҗәлелек, бәйсезлек, ачыклык һәм хәбәрдарлык принципларына нигезләнә.»;

**2) 6 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

**«6 статья. Контроль-хисап палатасы рәисе һәм аудиторлары вазифаларына кандидатураларга таләпләр**

1. Контроль-хисап палатасы рәисе һәм аудиторы вазифасына түбәндәге квалификация таләпләренә туры килә торган Россия Федерациясе гражданнары билгеләнә:

1) югары белеме булган;

2) дәүләт, муниципаль идарә, дәүләт, муниципаль контроль (аудит), икътисад, финанс, юриспруденция өлкәсендә кимендә биш ел эш тәҗрибәсе;

3) Россия Федерациясе Конституциясен, федераль законнарны, шул исәптән Россия Федерациясенең бюджет законнарын һәм бюджет хокук

мөнәсәбәтләрен җайга сала торган башка норматив хокукый актларны, Россия Федерациясенең тиешле субъекты законнарын һәм башка норматив хокукый актларны, тиешле муниципаль берәмлек уставын һәм вазифаи бурычларны үтәүгә карата башка муниципаль хокукый актларны, шулай ук Россия Федерациясе Хисап палатасы раслаган Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль һәм эксперт-аналитик чараларын уздыру өчен тышкы дәүләт һәм муниципаль аудит (контроль) стандартларына карата гомуми таләпләрне белү.";

2. Россия Федерациясе гражданы түбәндәге очракларда контроль-хисап палатасы рәисе вазифасына билгеләнә алмый:

1) аның алынмаган яисә юкка чыгарылмаган хөкем ителүе булу;

2) аның закон көченә кергән суд карары буенча хокуктан файдалануга сәләтсез яисә хокуктан файдалану сәләте чикләнгән дип танылуы;

3) дәүләт серен тәшкил иткән һәм федераль закон белән саклана торган башка серне тәшкил иткән белешмәләрне күрә алуны рәсмиләштерү процедурасын узудан баш тартуы, әгәр гражданның дәгъвалана торган вазифасы мондый мәгълүматлардан файдалану белән бәйле булса;

4) Россия Федерациясе гражданлыгы туктатылу яисә чит ил дәүләте гражданлыгы (подданствосы) яки яшәүгә рөхсәт яисә Россия Федерациясе гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукынраслый торган башка документы булу;

5) әлеге статьяның 3 һәм 4 өлешләрендә каралган нигезләр булу.

3. Контроль-хисап палатасы рәисе һәм аудиторы вазифаларын биләүче гражданнар муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы рәисе, муниципаль берәмлек башлыгы, җирле администрация башлыгы, Арча муниципаль районы территориясендә урнашкан суд һәм хокук саклау органнары җитәкчеләре белән якын яки үги туганлыкта тора алмыйлар (ата-аналары, ире яки хатыны, балалары, бертуганнары, шулай ук иренең (хатынының) бертуганнары, ата-аналары, балалары).

4. Контроль-хисап палатасы рәисе һәм аудиторы, мөгаллимлек, фәнни һәм башка иҗат эшчәнлегеннән тыш, башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнә алмый. Шул ук вакытта мөгаллимлек, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлек, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, бары тик чит дәүләтләр, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары исәбеннән генә финанслана алмый.

5. Контроль-хисап палатасы рәисе һәм аудиторы, шулай ук күрсәтелгән вазифаларны биләүгә дәгъва кылучы затлар үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә белешмәләр тапшырырга тиеш.

6. Контроль-хисап палатасы рәисе һәм аудиторы белешмәләр тапшыру елы алдыннан килгән 3 календарь ел өчен (алга таба - хисап чоры) үзенең,

хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының алар тарафыннан кылынган җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар) сатып алуга киткән чыгымнары турында мәгълүмат бирергә бурычлы, сатып алуларның гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) хисап чорындагы гомуми кеременнән артып китсә, әлеге сатып алуларны башкару өчен тотылган акчаларны алу чыганаклары турында федераль законнарда һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, алар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә белешмәләр тапшырырга тиеш.";

"7. Контроль-хисап палатасы рәисенә һәм аудитына Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән муниципаль вазифаларны биләүгә бәйле чикләүләр һәм бурычлар кагыла.»;

**3) 7 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«2. Контроль-хисап органы тәкъдимен яисә күрсәтмәсен үтәмәү Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән җаваплылыкка китерә.»;

**4) 8 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

**«8 статья. Контроль-хисап палатасының вәкаләтләре**

1. Контроль-хисап палатасы түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

1) җирле бюджет чараларының, шулай ук Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда, башка чараларның законлылыгын һәм нәтиҗәлелеген тикшереп торуны оештыру һәм гамәлгә ашыру;

2) җирле бюджет проектларына экспертиза үткәрү, аның күрсәткечләренең нигезлелеген тикшерү һәм анализлау;

3) җирле бюджет үтәлеше турында еллык хисапны тышкы тикшерү;

4) "Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында" 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу өлкәсенә аудит үткәрү;

5) муниципаль милекне формалаштыруның, мондый милек белән идарә итүнең һәм эш итүнең нәтиҗәлелеген бәяләү һәм мондый милекне формалаштыруның, идарә итүнең һәм аның белән эш итүнең билгеләнгән тәртибен (интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә аерым хокукларны да кертеп) үтәүне тикшереп тору;

6) җирле бюджет акчалары исәбеннән салым һәм башка ташламалар һәм өстенлекләр, бюджет кредитлары бирүнең нәтиҗәлелеген бәяләү, шулай ук муниципаль гарантияләр бирүнең һәм йөкләмәләрне юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар тарафыннан җирле бюджет акчалары һәм муниципаль милектәге мөлкәт исәбеннән башкарылган алыш-бирешләр буенча башка ысуллар белән үтәүне тәэмин итүнең законлылыгын бәяләү;

7) муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәләренә кагылышлы өлешендә муниципаль хокукый актлар проектларына, җирле бюджет керемнәрен үзгәртүгә китерә торган муниципаль хокукый актлар проектларына, шулай ук муниципаль программаларга (муниципаль программалар проектларына)

экспертиза үткәрү;

8) муниципаль берәмлектә бюджет процессын анализлау һәм мониторинглау, шул исәптән бюджет процессында ачыкланган тайпылышларны бетерү һәм Россия Федерациясе бюджет законнарын камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү;

9) квартал саен муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органына һәм муниципаль берәмлек башлыгына агымдагы финанс елда җирле бюджет үтәлешен оештыруны оператив анализлау һәм тикшереп тору, җирле бюджетның үтәлеше турында, үткәрелгән контроль һәм эксперт-аналитик чараларның нәтиҗәләре турында мәгълүмат тапшыру;

10) муниципаль эчке һәм тышкы бурычның торышын тикшереп тору;

11) муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы компетенциясе чикләрендә стратегик планлаштыру документларында каралган муниципаль берәмлекнең социаль-икътисади үсеше максатларына ирешүнең гамәлгә ашырылуын, куркынычларын һәм нәтиҗәләрен бәяләү;

12)вәкаләтләр чикләрендә коррупциягә каршы көрәшкә юнәлдерелгән чараларда катнашу;

13) федераль законнарда, Россия Федерациясе субъекты законнарында, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органының уставында һәм норматив хокукый актларында билгеләнгән тышкы муниципаль финанс контроле өлкәсендәге башка вәкаләтләр.

2. Контроль-хисап палатасы тарафыннан тышкы финанс контроле түбәндәгеләргә карата гамәлгә ашырыла:

1) җирле үзидарә органнарына һәм муниципаль органнарга, муниципаль учреждениеләргә һәм муниципаль унитар предприятиеләргә, шулай ук, әгәр алар муниципаль район милкендәге мөлкәттән файдалансалар, башка оешмаларга карата;

2) дәүләт хакимияте органнарына һәм дәүләт органнарына, бюджеттан тыш дәүләт территориаль фондлары органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм муниципаль органнарга, Россия Федерациясенең тиешле субъектының (муниципаль берәмлекнең) дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә һәм унитар предприятиеләренә, шулай ук, әгәр алар Россия Федерациясенең тиешле субъектының (муниципаль берәмлекнең) дәүләт (муниципаль) милкендәге мөлкәттән файдалансалар, башка оешмаларга карата;

3) сатып алулар өлкәсендә мониторинг һәм аудит формасында дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләрне сатып алучы учреждениеләргә карата.»;

**5) 17 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

**«17 статья. Контроль-хисап палатасының күрсәтмәләре һәм тәкъдимнәре**

1. Контроль-хисап палатасы тикшерү чаралары уздыру нәтиҗәләре буенча җирле үзидарә органнарына һәм муниципаль органнарга, оешмаларга һәм аларның вазифаи затларына ачыкланган бюджет һәм башка хокук бозуларны һәм җитешсезлекләрне бетерү, матди зыян ясауны булдырмау яисә китерелгән зыянны каплау чаралары, җибәрелгән хокук бозуларда гаепле вазифаи затларны җаваплылыкка тарту буенча тәкъдимнәр, шулай ук хокук бозуларны бетерү һәм

кисәтү чараларын күрү өчен күрсәтмәләр бирергә хокуклы.

2. Контроль-хисап палатасы күрсәтмәләре контроль-хисап палатасы рәисе тарафыннан имзалана.

3. Җирле үзидарә органнары һәм муниципаль органнар, күрсәтмәдә билгеләнгән срокта яки, әгәр срок күрсәтелмәгән булса, күрсәтмә алганнан соң 30 көн эчендә контроль-хисап палатасына күрсәтмәне үтәү нәтиҗәләре буенча кабул ителгән карарлар һәм чаралар турында язмача хәбәр итәргә тиеш.

4. Аларны кисәтү һәм булдырмау буенча кичектергесез чаралар күрү таләп ителә торган закон бозулар ачыкланган очракта, контроль-хисап палатасының вазифаи затларына тикшерү чаралары үткәрүгә комачаулау, шулай ук күрсәтмәләрне карау сроклары үтәлмәгән очракта, контроль-хисап палатасы җирле үзидарә органнарына һәм муниципаль органнарга, тикшерелә торган оешмаларга һәм аларның вазифаи затларына күрсәтмә җибәрә.

5. Контроль-хисап палатасы күрсәтмәсендә ясалган билгеле бер хокук бозуга һәм әлеге күрсәтмәне чыгаруга анык нигез булырга тиеш.

6. Контроль-хисап палатасы күрсәтмәсе контроль-хисап палатасы рәисе тарафыннан имзалана.

7. Контроль-хисап палатасы күрсәтмәсе анда билгеләнгән срокларда үтәлергә тиеш. Күрсәтмәне үтәү срогы контроль-хисап органы карары буенча озайтылырга мөмкин, ләкин бер тапкырдан да артык түгел.

8. Контроль-хисап палатасы күрсәтмәсен билгеләнгән срокта үтәмәү яисә тиешенчә үтәмәү Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән җаваплылыкка китерә.

9. Контроль чаралар уздырганда муниципаль район бюджеты акчаларын законсыз файдалану фактлары ачыкланган очракта, аларда җинаять яисә коррупциячел хокук бозу билгеләре булса, контроль-хисап палатасы тикшерү материалларын кичекмәстән хокук саклау органнарына тапшыра.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга  һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында (http:arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы башлыгы урынбасарына йөкләргә.

Арча муниципаль районы башлыгы,
Арча район Советы рәисе — И.Г. Нуриев